| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

«01» ноябрь, 2024 ел Алабуга шәһәре № 387

Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы каршындагы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 маендагы 346 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы Уставы нигезендә һәм Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы каршындагы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең һөнәри эшчәнлеген стимуллаштыру максатларында, Алабуга муниципаль районы Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2025 елның 1 гыйеварынннын Алабуга муниципаль районы Советының «Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы каршындагы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең хезмәте өчен түләүне оештыру һәм аның шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» 2019 елның 31 маендагы 346 номерлы карары белән расланган Нигезләмәдә билгеләнгән, Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы каршындагы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәте өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган айлык хезмәт хакы күләмен арттырырга һәм (Нигезләмәнең 1.3. пунктының 1 абзацына) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

«1.3. Алабуга муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы каршындагы үзәкләштерелгән бухгалтерия җитәкчеләренең һәм белгечләренең вазифаи окладлары түбәндәге күләмнәрдә билгеләнә:

| Җитәкчеләр һәм белгечләр вазифасы | Алабуга муниципаль районы Финанс-бюджет палатасының структур бүлекчәсе - үзәкләштерелгән бухгалтерия өчен |
|---|---|
| | Төп оклад, сумнарда |
| Структур бүлекчә җитәкчесе - баш хисапчы | 36 200 |
| Җитәкче урынбасары | 33 180 |
| Бүлек башлыгы | 30 500 |
| Бүлек башлыгы урынбасары | 28 050 |
| Әйдәп баручы исапчы, әйдәп баручы икътисадчы | 26 800 |
| Хисапчы,икътисадчы | 25 300 |

2. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү Алабуга муниципаль районы бюджетында тиешле финанс елына каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга тиеш һәм 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

4. 3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны икътисади үсеш, бюджет, салымнар, тариф сәясәте, эшкуарлыкка ярдәм итү мәсьәләләре буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Комиссия рәисе урынбасары Р.Л. Исланов